**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“25” ноябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Югары Шашы торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы авылы территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Югары Шашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- янгын гидранты һәм төзелеш материаллары сатып алу, урнаштыру, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү;

-урам утларын яктырту максатыннан лампалар,автоматлар, җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;

- авыл территориясен төзекләндерү, хезмәт өчен түләү (чүп үләннәрен чабу һәм чистарту);

- Гагарин урамы, 1 нче йорт каршындагы чокырны киртә белән әйләндереп алу.

(төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү);

- урам юлларындагы чокырларны ямау (вак таш сатып алу, җәю һәм транспорт

хезмәтләре өчен түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Югары Шашы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Күңгәр авыл җирлеге Советы
5 округ депутаты: Абдуллин Р.Х.